# Петровлар нәселеннән

**Илюткино авылында Петровлар —иң күп таралган фамилия. Зур нәселне берләштергән фамилия ул. Механизаторлар Василий Михайлович, Иван Иванович бар, терлекчелек буенча механик Анатолий һәм токарь Иван Петровлар да шул нәселдән. Һәммәсен эшсөярлек, тырышлык һәм гадел хезмәт берләштерә аларның. Арада берсе—Николай Михайлович турында аеруча җылы итеп сөйлиләр хуҗалыкта.**

Берүзенә өч техника исәпләнә Николай Михайловичта. Кыш көннәрендә ул ДТ-75 тракторында эшли. Чәчүдә Т-70кә күчә, ә урып-җыю вакытында аның буйсынуында КСК-100 була. Николай Михайлович шул өч техниканы да бердәй осталык белән иярли, эш төрен алыштырганда да чыгымчылаган ат кебек тәртәгә тибә торган гадәте юк. Сабыр гына һәр эшкә җигелеп китә, аны ахырына җиткәнче башкара. Соңгы елларда ул нигездә кукуруз игү белән шөгыльләнә. Чәчүдә иптәше Вячеслав Прокофьев белән йокыны-ялны онытып эшлиләр. Азык әзерләү чорында янә ял тими аңа. Узган елны 1 бригадада кукуруз уңышы 380 центнер тәшкил итте—бу бит шул Николай Михайловичның тырышлыгы нәтиҗәсе. Тырышлык, хезмәт сөю нәселнең башыннан килә. Аларның да әтисе Михаил Павлович—бик тә булган, эшчән кеше иде. «Атказанган колхозчы» исемен алып китте ул лаеклы ялга. Үзе китте, ә урынына ничә Петровны калдырды. 7 бала үсте бу гаиләдә. Хәзер 5се авылда яши. Олы апалары Нина хәзер үзе лаеклы ялда инде. Юлия—бозаулар карый, Анна—терлекче дә, башка эштән дә йөз чөерми. Тагы бер туганнары—Василий Михайлович —шулай ук механизатор. Белемле, дәрәҗәле кеше колхозда. Ә Николай Михайлович турында әйтеп тә торасы юк.

—Алтын куллы кеше,—ди колхоз председателе Анатолий Германович Гаврилов аның турында. Үзе механизатор, үзе эретеп ябыштыручы. Фермада төзексезлекләр чыкканда да аңа егылабыз. Бөтен төр яңа техниканы да иң элек ул үзләштерә.

Председатель, сүзен раслап, машина-трактор паркында читтәрәк торган техникага күрсәтте. Ул ПНД автотөягече икән, әле яңа гына кайткан. Николай Михайлович нәкъ шуны көйләү белән мәшгуль бу көннәрдә. Кайчандыр КСК-100не дә районда беренчеләрдән булып ул сынап караган булган.

Николай Михайлович үзе әңгәмәгә сирәк кушыла. Авыл тормышы белән кызыксынгач кына йөзе җанланып китә аның. Илюткино бит теге еллар политикасы дәвам иткәндә бетүгә, таралуга дучар ителгән авыл иде. Шөкер, хәзер аңа акрынлап җан иңеп килә, авылда төпләнергә теләүчеләр дә арта тора. Ул үзе дә дөнья күреп, ерак Златоуст калаларында эшләп карагач кына инанды авылның аның өчен төп төбәк икәнлегенә. Дөрес, бу хәлләр күптән булды инде. Механизатор булып эшли башлавына да 10—12 еллар булыр. Хәзер үзенең 5 баласы, өлкәне Юрий быел җәй комбайнчы ярдәмчесе булып эшләде. Булдырыр сыман күренә егет, ата кеше канәгать калды аның хезмәтеннән. Кем белә, бәлки ул да Петровларның нәсел һөнәрен дәвам итүче яшь механизатор булыр? Хәер ата кеше моны шарт итеп куймый. Укысын, теләсә нинди һөнәр сайласын, әмма җирдән аерылырга тырышмасын. Җир кешене беркайчан алдамый. Үзенең 4 улына да бу сүзләрне еш кабатлый Николай Михайлович. Мисалга 99 нчы СПТУда укып йөрүче колхоз стипендиатлары Сергей Чернов, Александр Семибратов, Александр Прокопьев кебек яшьләрне китерә. Алар колхозның киләчәген тәэмин итәсе кешеләр бит. Шулар арасында Петровлар да һичшиксез булырга тиеш!

Николай Михайлович моны бар күңеле белән аңлый. Сабыр холыклы, һәр сүзен исәпләп сөйләргә гадәтләнгән игенче дәвамын туган төбәгендә, җирдә ныгытырга тели.

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

## Шундый-шундый хәлләр бар...

# Ни Әхмәткә, ни Илюткинога...

«Москва» колхозына кергән Илюткино һәм Әхмәт авылларының хуҗасы кем? Эзләп маташмагыз әллә нигә таба алмыйсыз. Чөнки ике авыл—ике авыл Советы карамагында кече авыл хокукында яши. Илюткино Бикүле авыл Советына караса, Әхмәт Аксумлага керә. Билгеле инде, бу авыл Советлары иң элек үзләре урнашкан торак пунктны кайгырталар, биредә бик сирәк кунак алар. Шулай итеп, авыл Советы үзәге булып кайгырту тоеп яшәү ни Әхмәткә, ни Илюткинога насыйп булмас, ахры...

# Әхмәтнең иң „тарихи" бинасы

Сез я мәчет, я мәктәптер дип уйлыйсыздыр инде. Ялгышасыз. Бик тә заманча «тарихи» бина ул. Шәһәрлеләр бәлки үзәк стадионда бер кабарып, бер шиңеп утырган өреп бастырган «бинаны» хәтерлиләрдер. Менә шул 54 мең сумлык могҗиза ниндидер язмыш белән «Большевик» колхозына килеп керә һәм, билгеле инде, әлеге колхоз «яхшы» товарны Әхмәткә склад бинасы итеп «бүләк итә». Гадәттәгечә, Әхмәттә җил исә, ут сүнә, кабарып утырган склад та шиңә, шуннан кар-яңгырлар китә һәм 54 мең сумлык «байлык» җил-яңгыр белән юылып җир өстеннән дә югала.

# Төзү сүтү түгел шул

634нче СМП өченче ел инде Әхмәт авылында бозаулату бүлеге төзи. Өченче ел ферма һаман төзелеп бетә алмый, ә бозаулыйсы сыерлар ат абзарында бозаулый торалар.

Аның каравы, кайчандыр «төзегәнне» бик тиз җимергән булганнар. Әхмәт авылындагы бер сарык фермасы сүтеп, кирпечен... Аксумлада мәктәп төзелешенә тоткан булганнар—бу хакта авыл халкы хәзер дә хәтерли әле.

## Ветеран сүз ала

# Тәртипне яклыйбыз

Сугышка мин бик яшьли киттем. 19 яшем тулган көнне инде яраланып госпитальдә ята идем. 1 нче Белоруссия, 2 нче Белоруссия фронтларында Берлингача барып җиттем. Мин хезмәт иткән 61 нче армия шуннан Ерак Көнчыгышка китте, мин янә яраланып госпитальдә калдым. Хәрби хезмәт әле минем өчен Дрезденда 50 нче елга кадәр дәвам итте. Нәкъ шул елны безнең «Верхний» колхозын «Москва» колхозына куштылар. Аңарчы хуҗалыгыбыз алдынгы иде, 2 бригада исәпләндек. Шул кушылудан башланды да инде безнең кагылып-сугылып йөрүләр. Аннан «Большевик»ка күчерделәр. Анда 150 колхозчы белән 65 йорт булып килеп кергән идек—хәзер әнә күрәсездер: 40—45 йорт, 60—65 колхозчы калды авылда. Әле без соңгы 1—2 елда барыбер авылга җан иңде, дип сөйлибез. Янәшәбездән асфальт юл үтүе дә сәбәпче булгандыр моңа, киредән бер «Москва» колхозы итеп берләшүнең дә йогынтысы тигәндер дип уйлыйм. Ни дисәң дә хәзер безгә дә игътибар күрсәтә башладылар бит инде. Әнә акрын гына булса да төзелешләр алып барыла. Колхоз рәисе А. Г. Гаврилов яңа кайткан – 5 йортның 2сен шулай ук безнең авылга була дип тора. Анысы бик кирәк. Мин шулай уйлыйм: торак йортлар булса, авыл терелергә тиеш. Үзебезнең гаилә мисалында да шулай ул. Әнә малаем Хәлил фермада оператор булып эшли. Читтә яшәүче кызым да гаиләсе белән кайтып урнашты. Хәер, урнашты дию үк дөрес булмас—әлеге дә баягы йорт кирәк аларга, йорт. Ә калыр теләкләре зур, эшче куллар колхозга да бик кирәк. Безнең буын белән генә әлләни майтарып булмый. Авылга 4 ветеран калдык. Аның икесе—1 нче группа инвалид, икебез—икенче группа. Мин үземнең тәнемдә 7 кыйпылчык ярасы йөртәм. Гомерем буе хәлемнән килгәнчә эшләдем—ферма мөдире дә булдым, бригадир да, каравылда да тордым. Сугыш безнең кебек малайларны иртә олыгайтты, иртә картайтты. Аның телгә алырлык истәлекләре дә җитәрлек. Үзебезне дә искә алгалыйлар алуын. Бер елны хәтта Германиягә Эльба буенда очрашуга чакыру да килгән иде. Шунда хәтер калдыргыч бер нәрсә булып алды: минем анда булуым-булмавымны төпченә-тикшерә күрешү срогы минсез генә үтеп тә китте.. Фронтташлар белән очрашканда зыян итмәгән булыр иде дә бит! Узган эшкә салават инде. Алай бик зарланырга яратмыйм мин үзем. Карчык кына кайчак: пенсияләр аз, дип куя. Кибеткә ветераннар өчен тиешле продуктлар кайтмавына да ул күбрәк көенә. Анысы шулай инде, продукцияне үзвакытында ала алганыбыз юк. Кибетчебез әйтә: 4 кеше әйберен алыр өчен Егоркинога (безнең РТП шунда була инде) йөри алмыйм инде, ди. Ул да үзенчә хаклы. Күрәсең, шул ярты килограмм майны да кеше борчымыйча гына тапшырырлык ясау җае юк сәүдә системасында.

Ярар, болары—сүз иярә чыккан сүзләр генә. Өлкәннәр шулай күп күрә, күп белә инде алар.

Ч. ХӘЙБУЛЛИН,
Бөек Ватан сугышы ветераны.



# Битараф була алмыйбыз

Мин—шул авылда туып-үскән, шунда 32 ел буе тракторчы булып эшләгән кеше. Гомер буе җир сөрдем, икмәк иктем, шунда тормышлы булдым, балалар үстердем. Болар һәммәсе сизелмичә үттеләр дә киттеләр. Хәзер туктап үз-үземә карасам—чәч агарган, дәрман беткән, исәнлек тә әлләкем түгел. Бары бер нәрсә тынычландыра: ярар, гомер заяга узмаган, балалар үсеп кеше булган. Әнә улым Вазыйх биредә, авылда ук калды. Хәзер Т-70 тракторында эшли. Ике малай Норлатта эшләп йөриләр.

Авыл тормышының, крестьян хезмәтенең төрле чагын күрдек. Чын ышанып әйтәм: әгәр тагы 10 ел элекке система, әүвәлге тәртипләр белән яшәсәк, авыл тәмам кафтаер, бетәр иде. Хәзер бераз яхшыга өмет уянып килә күңелдә. Әмма эшчеләр кирәк, яшьләр кирәк. Хәзер безнең Әхмәт бригадасында бер механизаторга 2 шәр техника, алай гына да түгел, кайбер иптәшләр техниканы калдырып терлекчелеккә килергә мәҗбүр булдылар. Минем үземә дә шулай туры килде. Инде менә Мингазыйм Галәветдинов белән бергә сарыклар карыйбыз. Мингазыйм 16 ел сарыкчылыкта эшләгән, бу хезмәтнең бөтен нечкәлекләрен белә. Кулдаш буларак та бик әйбәт: ярдәмчел, киңәш табышка җайлы. Эшне дә бүлешмибез, вакыт белән дә исәпләшмибез. Сәгать 4 нче яртыда фермада булабыз, көн шунда үтә. Хәзер безнең җаваплылыкта 450 баш мал бар. Шөкер, бәрәннәр сау-сәламәт үсә маллар да көр. Әле менә бүген Мингазыйм колхоздан үзебезгә премия итеп бирелгән сарыкларны алырга китте. Аңа—үткән ел терлекчелектәге хезмәтләре өчен, ә мин узган ел колхозның сөрү техникасында эшләүче тракторчылар арасында беренче урынга чыккан идем. Шуңа әле күптән түгел генә район Мактау тактасына фотога да төшеп кайттык. Рәхмәт хуҗалык җитәкчеләренә эшләгән кешегә шулай хөрмәт күрсәткән өчен.

Элек ул эшли, дә эшли идек, хәзер стимул дигән нәрсәне дә күтә күңел. Әнә безнең бригада чөгендерчеләре быел уңышны артыграк алдылар, ә апайларның күңелен күрергә оныттылар!

Тагы бер кызык кына фикер килеп тора әле башка. Безнең авылда иясез йортларны шәһәр халкы дача итеп ала башлады хәзер. Бер сүз юк, бу закон нигезендә рөхсәт ителә. Тик аларны авыл беркайчан да үз итә алмаячак, минемчә. Җәйге челләдә кылны кырыкка ярыр чакта авыл уртасында (әйе, шул сәбәпле яңа йорт салучыларга урын авыл читеннән бирелә) дачниклар кызынып яталар, ә хатын-кыз, бала-чага тир түгеп 8әр гектар чөгендер эшлиләр. Менә, мәйтәм, әлеге дачникларга 1 әр генә гектар булса да чөгендер бүлеп бирергә! Җирдән файдаланалар икән, хезмәтләре керсен.

Без биредә картаясы кешеләр, балаларыбыз шунда яши—шуңа да авылның киләчәгенә битараф була алмыйбыз.

В. ЖИРҖИЗОВ,

Рәсемдә: «Москва» колхозы терлекчеләре КПСС члены Вәгыйзь Гаязович Жирҗизов һәм Мингазыйм Шәрифуллович Галәветдинов.

# Белгечләр кирәк

Илюткино клубы 150 урынга исәпләнгән, аны яшьләрнең ял үзәге итү өчен шартлар да юк түгел. Әмма клуб әле андый бурычны үтәп житкерә алмый.

—Белгечләр юк,—ди колхоз рәисе А. Г. Гаврилов. Ә әлеге эшләп торучылардан инициатива да, теләк тә, омтылыш та күп сорала шул әле.



# Нәүруз мөбарәкбад!

Нәүруз... Бу исем ят та, таныш та. Борын-борынгыдан әби-бабаларыбыз үткәргән бәйрәм ул. Әмма без аны онытканбыз. Төрки бабаларыбыз яңа ел каршылап Нәүруз бәйрәм иткәннәр. Ул вакытларда исә яңа ел... яздан башланган. Бәйрәм сәгате 22 нче мартта—көн һәм төн тигезләшкән вакытта суга.

Борынгылар бәйрәмне атна буе дәвам иткәннәр. Һәр көннең үз гадәте, үз тәртибе, язылмаган кануннары булган: җиде көн буена гайбәт сөйләшмәгәннәр, каргыш теләмәгәннәр, туган-тумачаларга миһербанлык күрсәткәннәр, ата-баба каберенә барганнар, сугышлар тукталып торган...

Нәүруз бәйрәменең үзәгендә —«нәүруз әйтеп» пай (ашлык,азык-төлек) җыю. Ул нәүрузның күңелен күрү һәм пайга китерелгән әйберләрне Нәүруз арттырсын өчен эшләнә.

Әйдәгез әле, онытылган бәйрәмне кире кайтарыйк. Ата-бабаларыбыз үз иткән Нәүрузны нигә әле читкә кагарга?! Урыс кышларын күп озаттык, җитәр. Үзебезнең язны каршыларга вакыт.

22 нче март көнне авылыгыз, шәһәрегез гөрләп торсын әле. Изге сәгатьтә!

**Рифә ХАРРАСОВА,**
КДУ аспиранты.
(«Ялкын» журналы, 1991 ел, №2).

## Тешләшә торган юллар

**АТА ЗАРЫ**

**—Тәртипле бул!**
**Тәртипле бул!**
**«Өф» иттереп кенә йөрттек:**
**Күпме акыл биргән идек,—**
**шуны югалткан бит—өтек!**
**Акылга шул булды—китек...**

**ТАПШЫРДЫ**

**Хыялларын**
**дошманның ул**
**Шулай тормышка ашырды:**
**—Язмышлардан узмыш юк!**
**—дип,**
**Язмышка үзен тапшырды.**

# „Умырзая“ яши

Район футболчылары арасындагы популяр бу уенның тарихы түбәндәгечә. Егоркино мәктәбенә укытучы Алексей Павлович Давыдов килгәч, «Россия» колхозы футболчыларының кар өстендә күнегүләре даими төс алды. Егетләр кышкы күнегүләргә теләп йөрделәр, район беренчелегенә үткәрелгән җәйге футбол ярышларында да уңышлы чыгыш ясый башладылар. 1968—70 елларда алар НУРБның «Нефтьче», шикәр заводының «Спартак» командаларын чакырып, алар белән тигез уен осталыгы күрсәттеләр. 1972 елда районда беренче тапкыр кар өстендә футбол буенча турнир үткәрелде. Аның инициаторлары «Россия» колхозының спорт энтузиастлары булдылар, ул чактагы спорткомитет рәисе П.В. Казаков һәм «Урожай» ирекле спорт җәмгыяте рәисе Н. М. Михайлов бу идеяне тормышка ашыруда булыштылар. Беренче турнирда «Нефтьче», «Спартак» командалары белән бергә «Россия» һәм «Дружба» колхозлары вәкилләре көч сынаштылар. Ярыш «Россия» колхозы спортчыларының җиңүе белән тәгәлләнде. Шул чактан бирле турнир «Умырзая» исеме белән йөртелә башлады һәм ул һәр елны үткәрелеп килде. Анда катнашучылар саны да елдан-ел артты, призерлар үзгәрә торды, тамашачылар—болельщиклар ишәйде.

Иң даими болельщикларның берсе—«Россия» колхозының профком председателе, өч дәрәҗә Дан ордены кавалеры Павел Егорович Михеев иде. Ул 1912 елда Егоркино авылында туган, 1934—36 елларда хәрби хезмәттә була. Сугышка кадәр Октябрь МТСында трактор бригадасы бригадиры булып эшли. 1941 елның декабреннән сугыш ахырына кадәр фронтта була. Берничә тапкыр яралана, танкта яна, Одерны кичә. Берлин эчендәге көрәштә гвардия старшинасы П. Е. Михеевның Т-34 танкы экипажы ут һәм гусеница белән дошманның ике танкын, җиде пушкасын, унсигез автомашинасын юк итә, кырыклап солдат һәм офицерны кыра. Ватан алдындагы югары сугышчан хезмәтләре өчен ул өч дәрәҗә Дан ордены һәм күп медальләр белән бүләкләнә. 1945 елдан 1976 елга кадәр, пенсиягә киткәнче, ул «Россия» колхозында трактор бригадасы бригадиры, механика мастерское мөдире, профком председателе, техника куркынычсызлыгы буенча инженер вазифаларын башкара. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр колхозның иҗтимагый-политик тормышында актив катнаша. 1978 елда, 66 нчы яшендә ул вафат була. Ә «Россия» колхозының ВЛКСМ комитеты, авыл кешеләренең фикерләрен искә алып, 1980 елдан кышкы футбол буенча ярышларда П. Е. Михеев исемендәге приз булдырды һәм һәр елны ярышлар үткәрергә карар кылды.

Быелгы ярышларны профком председателе В.Н. Григорьев, спорт методисты Н. П. Мандрейкин һәм мәктәпнең физкультура укытучысы Н. М. Трофимов оештырдылар.

10 мартта үткәрелгән турнирда 10 команда катнашты. Алар элеккечә 15 әр минутлы 2 шәр тайм уйнадылар. Беренче турда оттырган командалар тамашачылар исәбенә күчтеләр. Бу Олимпия системасы уен ахырынача дәвам итте.

Ике тур үткәч, финалда бу призны уйнату тарихында беренче тапкыр 2 шәһәр—«Спартак» (шикәр заводы) һәм 53 нче СМУ командалары очрашты. Алар арасындагы кискен көрәш ничьяга бетте, ә матчта пенальтины заводлылар әйбәт үткәрделәр һәм төп призга лаек булдылар. Икенче урынга—53 нче СМУ, өченчегә—«Заря» колхозы командалары чыкты.

Күнегүләр җитмәве үзен сиздерсә дә, спортчылар тулаем алганда кызыклы, җанлы гына уен күрсәтә алдылар.

Турнир нәтиҗәләре буенча иң оста футболчылар да билгеләнде. Иң яхшы капкачы дип «Спартак»тан Чернов, иң яхшы сакчы шуннан ук Б. Б. Борисов, иң яхшы ярымсакчы—«Ветеран»нан В. П. Трофимов, һөҗүмче—«Заря»дан Матвеев, бомбардир —«Спартак»тан В.Азяков табылды. Алар кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнделәр.

Инде «Умырзая»ны оештыручы һәм анда иң әүвәл катнашучыларның берсе буларак, үземнең берничә теләгемне дә әйтәсем килә. Кышкы футбол буенча күнегүләргә иң җитди игътибар бирергә кирәк, чөнки ул—сәламәтлек нигезе. Сүзләремне раслау өчен мисалга «Ветеран» командасын китерәсем килә. Әлеге команда уенчылары — «Умырзая»ның иң беренче ярышларында катнашкан кешеләр. Төрле елларда алар җыелма команда составында «Россия» колхозы, район һәм республика данын яклап чыгыш ясадылар, «Урожай» ирекле спорт җәмгыяте коллективлары арасында РСФСР беренчелегендә призлы урыннарны алдылар. Узган ел «Умырзая» турнирында алар янә үз сәләтләрен, картаймас рухларын күрсәтеп, 1 урынга чыктылар, быелгы күрсәткечләре дә начар түгел. Менә алар —һич картаймас энтузиастларыбыз: А. С. Корчуков, А. С. Терентьев, В. М. Кадяшев, В.Н. Григорьев, В. В. Иванов, В. П. Трофимов, В. И. Матюшкин, Г. К. Киргизов, А. П. Корчуков В. В. Михеев, В. В. Павлов, Н. Н. Олопов.

Сәламәтлек һәм көр күңел сезгә, ә «Умырзая»га —озын спорт язмышы!

**В. ЕНДИРЯКОВ,**
«Россия» колхозы партия оешмасы секретаре.



И, урын булмады инде
Шул бичара бүреккә.
Әле генә карда иде,
Инде менә—Фәриттә.
Бигрәк шук та булды да
бит
Өлгермисең күреп тә
Белмим, кем кемгә охшаган:
Әллә бүрек Фәриткә?
Әллә Фәрит бүреккә?

А. Сасин фотоэтюды.

# Телевидение

**ШИМБӘ**
**23 МАРТ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

19.00 «Татарстан».
19.30 Әлли-бәлли-бәү.
19.40 Халык талантларының III Бөтенсоюз фестивале. Тукай районы үзешчән сәнгатьтә катнашучылар чыгышы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Россия тавышлары» телерадио конкурсы лауреаты Н. Крыгина җырлый.
6.45 Мультфильмнар.
7.15 «Спорт һәркем өчен».
7.30 Ритмлы гимнастика.
8.00 Иртәнге күңел ачу программасы.
8.30 «Сәламәтлек».
9.15 Режиссер С.Самсонов фильмнары. «Оптимистик трагедия».
11.10 «Таң йолдызы».
12.10 Телевизион документаль фильм: «Шахматчы көзе».
13.10 Мультфильмнар.
14.40 Документаль фильм премьерасы.
15.15 Фотоконкурс: «Җир —уртак йортыбыз».
15.20 «Образ». Өлкән класста укучылар өчен әдәби тапшыру.
16.35 «Иллюзион аттракцион».
18.00 Халыкара панорама.
18.45 Нәфис фильм: «Кичерү турында үтенечкә карата аңлатма».
21.00 «Вакыт».
21.45 «Мәхәббәтнең мәңгелек җыры». Һиндстан фильмнарын яратучылар өчен киноконцерт.
22.45 «Деррик» сериясеннән нәфис телефильм. «Амстердамнан килгән ханым».
00.05 «А» программасы. Роджер Уотерс. «Стена».
00.55 Нәфис телефильм: «Өлкән угыл». 1 серия.

**II ПРОГРАММА**

8.15 Мультфильм.
8.25 Союздаш республикаларның кинопублицистикасы.
9.00 «Телевидение ТВ турында».
10.00 «Хезмәттәшлек» видеоканалы.
13.30 «Плюс унбер» видеоканалы.
17.00 Футбол. СССР чемпионаты. «Черноморец»—«Динамо» (Мәскәү).
18.50 Телепрограмма «Гаилә».
21.45 «Ялта-91».

**ЯКШӘМБЕ**
**24 МАРТ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 ТССРның халык артисты Ш. Әхмәтҗанов бенефисы.
19.35 Әлли-бәлли-бәү.
19.45 «Әти, әни һәм мин— —музыкаль гаилә». Гаилә ансамбльләренең республика смотры йомгаклау концерты.

**I ПРОГРАММА**

8.15 Ритмлы гимнастика.
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 «Иртән-иртүк».
10.00 «Ватанга хезмәттә».
11.00 «Иртәнге күңел ачу программасы».
11.30 Сәяхәтчеләр клубы.
13.00 «Авыл сәгате».
14.00 «Музыкаль киоск».
14.30 «Алып бар».
15.15 «Марафон-15».
16.30 «Беренче телевидениенең променад концерты».
18.10 «Уолт Дисней күрсәтә...»
19.00 Документаль фильм премьерасы «Риваять». Мультфильм премьерасы «Янутлар» (Канада).
19.50 Нәфис фильм: «Шерлок Холмс һәм яңа корал».
21.00 «Вакыт».
21.45 Футбол күзәтү.
22.15 «Телевизион танышу». СССРның халык артисты В. Спиваков.
23.35 «ВИД» «Шоу-биржа» музыкаль программасын тәкъдим итә.
00.55 «Бер биографиядән өзекләр». Аргентина композиторлары музыкасына фильм-балет.
01.45 Нәфис телефильм: «Өлкән угыл». 2 серия.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Мультфильм.
8.30 Концерт.
9.30 Документаль фильм.
10.05 Нәфис фильм.
11.15 «Плюс унбер» видеоканалы.
14.45 Мультфильм.
15.00 «Без яши торган дөнья». Режиссер Ю. Нагибин фильмнары: «Музей сурәте». «Дивертисмент».
16.00 НБА профессионаллары арасында баскетбол буенча АКШ чемпионаты.
21.45 Авторлык телевидениесе.
23.45 Җиңел атлетика.

## КӨЛЕШЕП АЛЫЙК

**КАБАК ТЫШЫННАН...**

ГФР селекционерлары гаҗәеп ачыш ясаган. Алар үстергән кабакның тышы шулкадәр ныклы булып чыккан, аны хәтта аяк киеме табаны буларак кулланырга уйлыйлар. Кабык ныклы булу белән бергә бик күркәм һәм йомшак икән. Аны тире эшкәрткән кебек эшкәртергә мөмкин. Мондый материалдан эшләнгән табанлы аяк киемнәрен күпләп чыгара башлауга әле ерак булса да, селекционерлар лабораториясендә беренче ботинкалау сынау үтә башлаган да инде.

**Норлат газ службасы коллективы эниләре**
**МӘРЗИЯ СӘЛИХҖАН кызы**
**ХӘМӘТВӘЛИЕВАның**
**вафат булуы сәбәпле Хәмәтвәлиевлар гаиләсенең тирән кайгысын уртаклаша.**

Мөхәррир урынбасары **Р. З. АЙЗАТУЛЛИН.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 32. Тираж 3.350.**